**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
УЗЯКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Хазиева ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Хәҗиев ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053615 ОГРН 1061675010165 ИНН/КПП 1619004370/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№38**

**КАРАР
«25» июль 2019 г.**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Үзәк п., Татарстан ур., 7, авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;
-Үзәк п., Хаҗиев ур., авыл җирлегенең игъланнар тактасы;
-Шармыш авылы, Школьная урамы,43 нче йорт, Шармыш авыл клубы бинасында мәгълүмат стенды;
-Сауш авылы, Гарифуллин урамы, 20 йорт, авыл клубы бинасында игъланнар тактасы;
-Алга авылы, Мрясов ур., 6, фельдшер-акушерлык пункты һәм алга башлангыч мәктәбе бинасында.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Үзәк  авылы, Татарстан урамы, 7 йорт, Үзәк авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Үзәк авыл җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Үзәк  авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.Н.Котников